Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге составына керүче Урта Чаллы торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2023 елның 11 ноябре № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлегенең Урта Чаллы торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Кызыл Чапчак авыл җирлеге Урта Чаллы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире/хатынынан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны чишмәне һәм ял итү зонасын төзекләндерүгә юнәлдерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кызыл Чапчак авыл җирлеге башлыгы Б.В.Ильдарханов